Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Чәчәкле авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР

27.03.2025 № 7

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Чәчәкле авыл җирлеге башкарма комитетының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Чәчәкле авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Чәчәкле авыл җирлеге башкарма комитетының түбәндәге карарларының үз көчләрен югалтуын танырга:

1.1. «Җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектын файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү регламентының административ» регламентын раслау турында» 2021 елның 22 июлендәге 16 номерлы;

1.2. «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Чәчәкле авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 22 июлендәге 16 номерлы карары белән расланган җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 2022 елның 25 августындагы 21 номерлы карары.

2. Әлеге карарны ТР Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://spasskiy.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

Чәчәкле авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе: Р.Р.Фәисханов